МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«23» апреля 2010 г. № 1685/10

г. Казань

“Мин татарча сөйләшәм” республикакүләм конкурсы нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 нчы елның 26 нчы февралендәге 710/10 нчы боерыгы нигезендә урта, һөнәри белем бирү учреждениеләрендә, гомуми белем бирү мәктәпләрендә дәүләт теле буларак татар теленең кулланылу дәрәҗәсен киңәйтү, укучыларда татар теленә мәхәббәт тәрбияләү, татар телендә аралашуга чакыру максатында “Мин татарча сөйләшәм” республикакүләм конкурсы үткәрелде.

Конкурс комиссиясенә барлыгы 81 эш тәкъдим ителде.

Оештыру комитеты һәм жюри биргән материаллардан чыгып, БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дипломын һәм истәлекле бүләген

I урынны алган

Зәй шәһәре 3 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенә

II урынны алган

Чаллы шәһәренең 19 нчы гомуми урта белем мәктәбенә

III урынны алган

Бөгелмә шәһәренең 2 нче лицее һәм Зәй шәһәренең 5 нче гомуми урта белем мәктәбенә бирергә.

2. Республика конкурсында яхшы әзерлек күрсәткән түбәндәге белем бирү учреждениеләрен билгеләп үтәргә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дипломын һәм истәлекле бүләген тапшырырга:

1. Казан шәһәренең 27 нче гимназиясенә
2. Менделеевск шәһәренең 2 нче гомуми урта белем мәктәбенә
3. Аксубай районының 2 нче гомуми урта белем мәктәбенә
4. Спасс районының Болгар 1 нче гомуми урта белем мәктәбенә
5. Алексеевск районының Биләр гомуми урта белем мәктәбенә
6. Югары Ослан гимназиясенә
7. Чүпрәле районы Татар Бизнәсе гомуми урта белем мәктәбенә
8. Казан шәһәренең 20 нче гимназиясенә
9. Яр Чаллы шәһәренең 79 нчы лицеена

10. Казан шәһәренең 68 нче гомуми урта белем мәктәбенә

11. Апас муниципаль районы 92 нче һөнәри белем бирү лицеена.

3. Боерыкны муниципаль район башкарма комитетларының мәгариф бүлекләренә, гомуми урта белем бирү мәктәпләренә җиткерергә.

4. Боерык үтәлүен тикшерүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Министрның беренче урынбасары Д.М. Мостафин

Г.Ф.Мусина
292–27–74